**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИККОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**25 март 2025 ел** **№ 95**

**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 32 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 30 мартыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында (https://nurlat.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында:

Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Биккол ав., Үзәк ур., 20 й урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биккол авыл җирлеге Советы Рәисе Р.Х.Әхмәтшина